Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы

КАРАР

2018 елның 13 ноябре № 30/14

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында” Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында” 2018 елның 13 октябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Чүпрәле районы прокурорының 2018 елның 31 октябрендәге 02-08-02-2018 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2014 елның 09 апрелендәге 40/9 номерлы карары белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **2 пунктта** «балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү.» сүзләрен «балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга, башка хокукка каршы һәм (яисә) җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү, шулай ук аларны суицидаль гамәлләргә тарту очраклары» сүзләренә алмаштырырга.;

2) **7 пунктның а пунктчасында:**

**җиденче абзацта** «хезмәт һәм» сүзләрен төшереп калдырырга, «дәүләт ярдәменнән соң» сүзләрен өстәргә «, балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру (аларның ризалыгы белән),»;

унынчы абзац киләсе редакциядә бәян итәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан балигъ булмаганнарны» Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда һәм аларны укытуга бәйле башка мәсьәләләрдә күчерү белән бәйле мәсьәләләрне карыйлар;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров